| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|
| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**<br>**17.02.2025** | Зеленодольск шәһәре | **КАРАР**<br>**№ 375** |

Комплексլы кадастр эшләрен башкарганда җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урынын килештерү өчен төзелә торган килештерү комиссиясе турында

2007 елның 27 июлендәге «Кадастр эшчәнлеге турында» 221-ФЗ номерлы Федераль законның 42.10 статьясы һәм 42.12 статьясы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Комплекслы кадастр эшләрен башкарганда җир кишәрлекләре чикләре урнашкан урынны килештерү өчен төзелә торган килештерү комиссиясе турында» 2015 елның 20 мартындагы 177 номерлы карары нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы территориясендә комплекслы кадастр эшләрен башкарганда җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урынын килештерү өчен төзелә торган килештерү комиссиясен әлеге карарга 1 нче кушымтада каралганча төзергә һәм расларга.
2. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы территориясендә комплекслы кадастр эшләрен башкарганда җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урынын килештерү өчен төзелә торган килештерү комиссиясе эше регламентын әлеге карарга 2 нче кушымтада каралганча расларга.
3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.
4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә дип билгеләргә.
5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче З.Ф. Хәбибуллин

Татарстан Республикасы
Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитеты карарына
1 нче кушымта

2025 елда Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы территориясендә комплекслы кадастр эшләрен башкарганда җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урынын килештерү өчен төзелә торган килештерү комиссиясе составы

| | | |
|---|---|---|
| Рәис | Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе | Хәбибуллин З. Ф. |
| Рәис урынбасары | Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары | Старостин А. В. |
| Секретарь | «Зеленодольск муниципаль районы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы» МУның җир мөнәсәбәтләре бүлеге башлыгы | Гатиятуллина А.С. |
| Комиссия әгъзалары: | | |
| Кыямов А.А. | Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министры урынбасары | |
| Габделхаков А.Р. | Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының кадастр эшләре бүлеге башлыгы | |
| Мөхәммәтҗанова Г.Х. | Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе территориаль бүлегенең Зеленодольск бүлеге башлыгы | |
| Мифтахов Т.И. | «Идел буе кадастр инженерлары ассоциациясе» үзлегеннән җайга салына торган оешма вәкиле | |
| Фәсхетдинов Р.Р. | Татарстан Республикасы һәм Ульяновск өлкәсендә дәүләт мөлкәте белән идарә итү буенча Федераль агентлыкның Федераль идарәсенең төбәкара территориаль идарәсе җитәкчесе урынбасары | |
| Алексахина А. Ю. | «Зеленодольск муниципаль районы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы» МУ җитәкчесе | |
| Сергеев П.Н. | «Зеленодольск муниципаль районы архитектура һәм шәһәр төзелеше сәясәте идарәсе» МБУ җитәкчесе | |
| Григорьева А.В. | Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Васильево шәһәр тибындагы поселогы Башкарма комитеты җитәкчесе | |
| Харинкин Ю.А. | Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Осиново авыл җирлеге Башлыгы | |
| Фәйзулина Ф.А. | Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Олы Җәке авыл җирлеге Башлыгы | |
| Демидова Е.В. | Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Әйшә авыл җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары | |
| Хисаметдинова Ф.Х. | Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Күгәй авыл җирлеге Башлыгы | |
| Мирхатуллин Ф.Ф. | Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Мамадыш-Әкил авыл җирлеге Башлыгы | |

Татарстан Республикасы
Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитеты карарына
2 нче кушымта

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы территориясендә комплекслы кадастр эшләрен башкарганда җир кишәрлекләре чикләре урнашкан урынны килештерү өчен төзелә торган килештерү комиссиясе эшенең регламенты

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. . Комплекслы кадастр эшләрен башкарганда җир кишәрлекләре чикләре урнашкан урынны килештерү өчен төзелә торган килештерү комиссиясе эшенең әлеге регламенты (алга таба – Регламент) «Кадастр эшчәнлеге турында» 2007 елның 24 июлендәге 221-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 221-ФЗ номерлы Федераль закон) нигезендә эшләнде.

1.2. Әлеге регламент комплекслы кадастр эшләрен башкарганда җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урынын килештерү буенча килештерү комиссиясе (алга таба - килештерү комиссиясе) составын, вәкаләтләрен һәм эш тәртибен билгели.

1.3. Килештерү комиссиясе үз эшчәнлегендә Россия Федерациясенең норматив хокукый актларына, Татарстан Республикасының норматив хокукый актларына, «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең норматив актларына, шулай ук Регламентка таяна.

1.4. Килештерү комиссиясенең эш максаты - комплекслы кадастр эшләрен башкарганда җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урынын килештерү. Чикләрнең урнашу урынын килештерү 221-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә урнашу чикләре мәҗбүри рәвештә килештерелергә тиешле җир кишәрлекләренә карата башкарыла.

## II. Килештерү комиссиясе вәкаләтләре

2. Килештерү комиссиясе вәкаләтләренә керә:

2.1.Түбәндәге хокукта чиктәш җир кишәрлекләренә ия булган кызыксынучы затларның җир кишәрлекләренең чикләре урнашуга карата каршы килә торган фикерләрне карау:

1) милек хокукындагы (дәүләт яки муниципаль милектәге чиктәш җир кишәрлекләре гражданнарга гомерлек мирас итеп биләүгә, даими (вакыты чикләнмәгән) файдалануга яисә дәүләт яисә муниципаль учреждениеләр булып тормаган юридик затларга яисә казна предприятиеләре тарафыннан даими (вакыты чикләнмәгән) файдалануга бирелгән очраклардан тыш);

2) гомерлек мирас итеп биләгән мирас хокукындагы;

3) даими (вакыты чикләнмәгән) файдалану хокукындагы (мондый чиктәш җир кишәрлекләре дәүләт яки муниципаль учреждениеләргә, казна предприятиеләренә, дәүләт хакимияте органнарына яисә җирле үзидарә органнарына даими (вакыты чикләнмәгән) файдалануга бирелгән очраклардан тыш);

4) аренда (әгәр мондый чиктәш җир кишәрлекләре дәүләт яки муниципаль милектә булса һәм тиешле аренда шартнамәсе биш елдан артык вакытка төзелгән булса) (алга таба - кызыксынучы затлар).

2.2.Регламентның 2.1 пунктында күрсәтелгән кызыксынучын затларның җир кишәрлекләре чикләре урнашу урынына карата каршы килә торган фикерләрне карау нәтиҗәләре турында, шул исәптән мондый каршы фикерләр дәлилсез булган

очракта, территориянең карта-планы проектын үзгәртүнең максатка яраксыз булуы яки мондый каршы килә торган фикерләр нигезендә территориянең комплексны кадастр карта-планын комплекслы кадастр эшләрен башкаручы тарафыннан үзгәртергә кирәк булу хакында килештерү комиссиясе бәяләмәсен әзерләү.

2.3.Комплекслы кадастр эшләрен башкарганда чикләрнең урнашу урынын килештерү актын рәсмиләштерү.

2.4. Регламентның 2.1 пунктында күрсәтелгән кызыксынучы затларга җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урыны турында җир бәхәсләрен суд тәртибендә хәл итү мөмкинлеге турында аңлату. .

## III. Килештерү комиссиясе составы, килештерү комиссиясе әгъзаларының вәкаләтләре

3.1. Килештерү комиссиясе рәисе булып Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесе тора.

3.2. Килештерү комиссиясе рәисе:

3.2.1. Килештерү комиссиясе эшчәнлегенә гомуми җитәкчелек итүне гамәлгә ашыра.

3.2.2. Килештерү комиссиясе эшчәнлеген планлаштыра, килештерү комиссиясе утырышының көн тәртибен раслый.

3.2.3. Килештерү комиссиясе утырышының көн тәртибендәге мәсьәләләрне карауны оештыра.

3.2.4. Карала торган мәсьәләләр буенча тәкъдимнәрне килештерүгә куя, тавыш бирүне оештыра һәм килештерү комиссиясе әгъзаларының тавышларын саный, аларның тавыш бирү нәтиҗәләрен билгели.

3.2.5. Килештерү комиссиясе исеменнән җибәрелә торган гарызнамәләрне, мөрәҗәгатьләрне һәм башка документларны язып куя.

3.3. Комиссия рәисе урында булмаса, аның вәкаләтләрен Комиссия рәисе урынбасары башкара.

3.4. Килештерү комиссиясе секретаре:

3.4.1. Килештерү комиссиясе утырышларында карау өчен материаллар әзерләүне оештыра.

3.4.2.Килештерү комиссиясе утырышының көн тәртибе проектын формалаштыра.

3.4.3. Килештерү комиссиясе әгъзаларына утырышны үткәрү вакыты һәм урыны турында, утырышның көн тәртибе турында хәбәр итә, утырышка әзерләнгән материаллар белән таныштыра.

3.4.4. Килештерү комиссиясенең утырышлар беркетмәләрен алып бара.

3.4.5. Җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урынына карата каршы килә торган фикерләрне карау нәтиҗәләре турында килештерү комиссиясе бәяләмәсен, комплекслы эшләрне башкарганда чикләрнең урнашу урынын килештерү актын әзерли.

3.4.6. Килештерү комиссиясе рәисе яисә килештерү комиссиясе рәисе урынбасарының килештерү комиссиясе эшчәнлеге белән бәйле башка төрле йөкләмәләрен башкара.

3.5. Килештерү комиссиясе әгъзалары.

3.5.1. Килештерү комиссиясе рәисе күрсәтмәсе нигезендә килештерү комиссиясе утырышларын әзерләүдә катнашалар.

3.5.2. Килештерү комиссиясе утырышларында катнашалар.

3.5.3. Утырышта катнашмаганда, утырышта карала торган мәсьәләләр буенча үз фикерен язма рәвештә җиткерәләр, ул утырышта игълан ителә һәм килештерү комиссиясе утырышы беркетмәсенә теркәлә.

3.6. Утырышта кабул ителгән карар белән килешмәгән очракта, килештерү комиссиясе әгъзалары үз фикерен язма рәвештә бәян итәргә хокуклы, ул килештерү комиссиясе утырышы беркетмәсенә мәҗбүри рәвештә теркәлергә тиеш.

## IV. Килештерү комиссиясенең эш тәртибе.

4.1. Җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урыннарын килештерү мәсьәләсе буенча комиссия утырышын үткәрү турында, шул исәптән территориянең карта-планы проектын әзерләү тәмамлану турында хәбәрнамәне үз эченә алган хәбәр комплекслы кадастр эшләре заказчысы тарафыннан күрсәтелгән утырыш уздырылган көнгә кадәр унбиш эш көненнән дә ким булмаган вакыт эчендә комплекслы кадастр эшләрен башкару башлану турында хәбәрнамәне бастырып чыгару, урнаштыру һәм җибәрү өчен Федераль законда билгеләнгән ысуллар белән бастырыла, урнаштырыла һәм җибәрелә.

4.2. Территориянең карта-планы проекты комплекслы кадастр эшләре заказчысы тарафыннан 221-ФЗ номерлы Федераль законның 42.10 статьясы 9 өлеше нигезендә килештерү комиссиясенә җибәрелә.

4.3. Килештерү комиссиясенең беренче утырышы комплекслы кадастр эшләре заказчысына территориянең карта-планы проекты кергән көннән утыз эш көненнән дә соңга калмыйча уздырыла. Килештерү комиссиясенең калган утырышлары кирәк булган саен уздырыла.

4.4. Килештерү комиссиясе теләсә нинди затларны территориянең карта-планы проекты белән таныштыруны түбәндәге юллар белән тәэмин итә:

4.4.1.Мөрәҗәгать итүче гарызнамәсе буенча электрон документ формасында территориянең карта-планы проектын юллау.

4.4.2. Килештерү комиссиясенең урнашу урыны буенча документ формасында территориянең карта-планы проекты белән танышу мөмкинлеген бирү.

4.5. Килештерү комиссиясе утырышында территориянең карта-планы проекты тәкъдим ителә, комплекслы кадастр эшләрен башкару нәтиҗәләре, җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урыннарын килештерү тәртибе һәм килештерү комиссиясенең эш регламенты аңлатыла.

4.6. Регламентның 2.1 пунктында күрсәтелгән кызыксынучы затларның 221-ФЗ номерлы Федераль законның 42.1 статьясы 1 өлеше 1 һәм 2 пунктларында күрсәтелгән җир кишәрлеге чикләренең урнашу урынына карата каршы килә торган фикерләре килештерү комиссиясе утырышын уздыру турында хәбәр басылып чыккан көннән алып әлеге утырыш уздырылган көнгә кадәр, шулай ук килештерү комиссиясенең беренче утырышы узган көннән алып утыз биш эш көне эчендә килештерү комиссиясенә язма рәвештә тапшырылырга мөмкин.

4.7. Җир кишәрлегенең урнашу урынына карата каршы килә торган фикерләр 221-ФЗ номерлы Федераль законның 42.10 статьясы 15 өлешендә күрсәтелгән белешмәләрне үз эченә алырга тиеш. Билгеләнгән сроктан соң килгән каршы килә торган фикерләр килештерү комиссиясе тарафыннан каралмый. Әлеге каршы килә торган фикерләрне караудан баш тарту турында хәбәрнамә әлеге каршы килә торган фикерләр кергән көннән алып өч эш көне эчендә кызыксынучы затка җибәрелә.

4.8. Җир кишәрлеге чикләре яки чикләренең өлешләре урнашкан урынны килештергәндә мондый чикләр яки аларның өлешләре урнашкан урын дип түбәндәгеләр санала:

4.8.1.Килештерелгән дип, әгәр җир кишәрлеге чикләре яки чикләренең өлешләре урнашкан урынга карата каршы килә торган фикерләр әлеге Регламентның 2.1 пунктында күрсәтелгән кызыксынучы затлар тарафыннан кертелмәсә, шулай ук әгәр мондый чикләр яки чикләрнең өлешләре урнашкан урын

законлы көченә кергән суд акты нигезендә билгеләнсә, шул исәптән җир кишәрлеге чикләре урнашкан урын турындагы җир бәхәсе каралуга бәйле рәвештә;

4.8.2. Бәхәсле дип, әгәр җир кишәрлеге чикләре яки чикләренең өлешләре урнашкан урынга карата каршы килә торган фикерләр әлеге 2.1 пунктында күрсәтелгән кызыксынучы затлар тарафыннан кертелсә, моңа җир кишәрлеге чикләре урнашкан урын турындагы җир бәхәсе суд тәртибендә хәл ителгән очраклар керми.

4.9. Килештерү комиссиясенең эш нәтиҗәләре буенча килештерү комиссиясе утырышы беркетмәсе Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгының 2015 елның 20 апрелендәге 244 номерлы боерыгы белән расланган форма буенча төзелә, шулай ук җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урынына карата каршы килә торган фикерләрне карау нәтиҗәләре турында килештерү комиссиясе бәяләмәсе төзелә, ул үз эченә түбәндәгеләрне ала:

4.9.1. Җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урынына карата кызыксынучы затларның каршы килә торган фикерләренең кыскача эчтәлеген.

4.9.2. Килештерү комиссиясенә тапшырылган материаллар турында мәгълүматны.

4.9.3. Килештерү комиссиясенең җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урынына карата кызыксынучы затларның каршы килә торган фикерләрен карау йомгаклары буенча, шул исәптән мондый каршы килә торган фикерләрнең нигезсезлеге очрагында территориянең карта-планы проектын үзгәртүнең максатка ярашсызлыгы турында яки башкаручының мондый каршы килә торган фикерләре нигезендә территориянең карта-планын комплекслы кадастр эшләрен үзгәртү кирәклеге турында нәтиҗәләрне.

4.10. Комплекслы кадастр эшләрен башкарганда чикләрнең урнашу урынын килештерү актлары һәм Регламентның 2 бүлегенең 2.2 һәм 2.3 пунктларында күрсәтелгән килештерү комиссиясе бәяләмәләре килештерү комиссиясе утырышын уздырган көннән алып биш эш көне эчендә кәгазь чыганактагы документлар рәвешендә рәсмиләштерелә, алар Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетында саклана.

4.11. Килештерү комиссиясе тарафыннан җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урынына карата кызыксынучы затларның каршы килә торган фикерләре нигезле булуга бәйле рәвештә территориянең карта-планы проектына комплекслы кадастр эшләрен башкаручы тарафыннан үзгәрешләр кертү кирәклеге турында карар кабул ителгән очракта, беркетмә һәм бәяләмә комплекслы кадастр эшләрен башкаручыга имзаланган көннән алып өч эш көне эчендә җибәрелә.

4.12. Территориянең карта-планы проекты ахыргы редакциядә комплекслы кадастр эшләрен башкаручы тарафыннан Регламентның 4.10 пунктында каралган документлар кергән көннән соң ун эш көне эчендә килештерү комиссиясе адресына җибәрелә. .

4.13. 221-ФЗ номерлы Федераль законның 42.10 статьясындагы 14 өлешендә каралган каршы килә торган фикерләрне бирү срогы чыккан көннән алып егерме эш көне эчендә килештерү комиссиясе комплекслы кадастр эшләре заказчысына территориянең карта-планы проектын ахыргы редакциясен һәм аны раслау өчен кирәкле булган килештерү комиссиясе утырышы материалларын җибәрә.

4.14. Килештерү комиссиясе утырышы, әгәр анда килештерү комиссиясе әгъзаларының яртысыннан артыгы катнашса, хокуклы дип санала.

4.15. Килештерү комиссиясе карарлары утырышта катнашучы килештерү комиссиясе әгъзаларыннан күпчелек тавышы белән кабул ителә һәм беркетмә белән рәсмиләштерелә. Килештерү комиссиясе әгъзаларының тавышлары тигез булганда, килештерү комиссиясе рәисе тавышы хәлиткеч булып тора.

## V. Йомгаклау нигезләмәләре.

5.1. Җир кишәрлекләре чикләре урнашу турында 221-ФЗ номерлы Федераль законның 42.10 статьясында каралган, аларга карата комплекслы кадастр эшләре башкарылган җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урыннарын килештерү нәтиҗәсендә җайга салынмаган җир бәхәсләре, комплекслы кадастр эшләрен башкарганда чикләрнең урнашу урынын килештерү актын рәсмиләштергәннән соң, суд тәртибендә хәл ителә.

5.2. Килештерү комиссиясе бәяләмәсенең булуы яки булмавы комплекслы кадастр эшләре башкарыла торган территориядә урнашкан җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урыны турында бәхәсләрне хәл итү өчен судка мөрәҗәгать итүгә комачауламый.